ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турындагы мәгълүмат хакында

Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе Э.Я. Вафинның Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Пенсия иминияте, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм бала табуга бәйле рәвештә социаль иминләштерү, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан социаль иминләштерү, гражданнарны социаль тәэмин итү буенча барлык социаль гарантияләрне тулы күләмдә һәм законнарда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

2.2. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан бирелә торган, шул исәптән проактив режимда һәм дәүләт хезмәтләрен, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре аша да, электрон рәвештәге дәүләт хезмәтләрен үз вакытында һәм сыйфатлы күрсәтүне тәэмин итәргә.

2.3. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан бирелә торган дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә мөрәҗәгать иткәндә гражданнарга хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру, процедураларны гадиләштерү һәм чыгымнарны

киметү максатларында дәүләт хакимияте органнары белән ведомствоара хезмәттәшлекне үстерүне дәвам итәргә.

2.4. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан бирелә торган дәүләт хезмәтләрен хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә өстенлекле тәртиптә күрсәтүне тәэмин итәргә.

2.5. Белешмәләрнең бердәй рәвеше составында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу өчен белешмәләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә кабул итүне тәэмин итәргә.

2.6. Ташламалы категорияләрдәге гражданнарны реабилитацияләүнең техник чаралары белән тәэмин итү, шул исәптән электрон сертификаттан файдаланып та, эшен дәвам итәргә.

2.7. «Гражданнар белән үзара эшләүнең бердәм элемтә үзәге» мәгълүмат системасын үстерүне дәвам итәргә.

2.8. Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын гамәлгә кертү проектында катнашуны дәвам итәргә.

2.9. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең клиент хезмәтләрендә өлкән буын өчен аралашу үзәкләрен булдыру буенча пилот проектын алга таба гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

2.10. Халык арасында пенсия тематикасы һәм социаль тематика буенча мәгълүмати-аңлатма эш, шул исәптән пенсия белән тәэмин итү һәм социаль тәэмин итү өлкәсендәге законнарны камилләштерү буенча дәүләт тарафыннан күрелә торган чаралар турында, Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе һәм ысуллары хакында, үткәрергә.

3. 2024 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты үз утырышында Татарстан Республикасында пенсия белән тәэмин итү һәм социаль тәэмин итү өлкәсендәге законнарны үтәү торышы турындагы мәсьәләне карарга тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2264-VI ДС